


Күптән түгел узган эчке эшләр оргәннары хезмәткәрләре Коне артыннан, участок уполномоченныйлары үзләренен һөнәри бәйрәмнәрен бил-геләп үттеләр. Үз эшенен белгечләре шул унайдан бүләкләнделәр. Алар арасында Радик Наиль улы Байчурин да.

Кадошкино полиция пунктынын 10нчы номерлы участок хезмәте- эчке эшләр органнары системасында ин моһимнәрнен берсе. Анын нигезен һәрвакыт үз эшенә тугры кешеләр тәшкил итә. Хәзерге вакытта участок бүлегендә оч хезмәткәр эшли. Яшь һәм перспективалы, үз эшенен белгечләре - полиция лейтенаты Р.Н.Байчурин, олкән лейтенант Д.В.Базаев һәм олкән участок полиция капитаны А.А.Тамбовцев.

- Без административ хокук бозулар турында беркетмәләр тозибез, кечкенә һәм урта авырлыктагы жинаятьләрне ачыклыйбыз һәм ачабыз, халыктан гаризалар һәм хәбәрләрне карыйбыз. Моннан тыш, безнен участокларда булган авыр жинаятьләрне тикшерергә булышабыз, - дип сойли үз һөнәре турында Р.Н.Байчурин.

Радик Наиль улы 10нчы номерлы Кадошкино полиция пунктынын учас-ток хезмәткәрләре арасында ин яше. Ул участковый булып 2018 елнын февраленнән эшли, әмма олкән коллегаларыннан тәжрибәне бик тиз кабул итә. Яшь кеше физика-математика факультетында укыган. Белгечлеге буенча информатика укытучысы. Аны район мәктәпләренә эшкә чакыралар, шулай да Радик участковый һөнәрен сайлый. Ә менә Мәскәү шәһәрендә эчке эшләр министрлыгынын эчке гаскәрләрендә хезмәт иткәннән сон, үзен нәкъ менә шушы олкәдә сынап карарга булган. Түбән Новгород академиясендә һөнәри әзерлек узган, анда физик әзерлек, ату күнекмәләренә ойрәнгән. Булачак полиция хезмәткәрен документлар алып барырга ойрәткәннәр. Р.Н.Байчурин икенче югары белем - юридик белем ала. Үзе билгеләп үткәнчә, ул, һичшиксез, хезмәттә кирәк.

Р.Н.Байчурин Паево, Глушково, Адашево, Насакан Потма, Большие Поляны, Латышовка, Птижская Слобода, Картлей торак пунктларына хезмәт күрсәтә. Үз участковыйларын барысы да күреп белә. Авылларда яшьләр күп түгел, ә олкән буынга да кайчак участковыйнын ярдәме кирәк була. Участковый еш кына хезмәт күрсәтүче участогы халкына торле конкүреш проб лемаларын хәл итүдә булыша. Халык белән эшләү, аерым алганда профилактика, участок полиция хезмәткәре һөнәрендә бик моһим. Ул һәрвакыт тынлый, ярдәм итә һәм болай ди:

- Участковыйнын эше документлар һәм халык белән эшләүгә бүленә, ос-тәвенә, кәгазьләр тутыру вакытнын ярты сыннан артыгын алып тора. Ә бит минем эшем - кабинет бүлмәсендә түгел, ә ижади, кызыклы. Бүген си-не нәрсә коткәнен беркайчан да бел-мисен, - дип елмая полицейский.

Коллективы турында әнгәмәдәшебез бары тик унай яктан гына сойли. Полиция бүлегендә белемле белгечләр, үз эшләрен яхшы белүчеләр, гадел һәм тәртипле, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзерләр. Һәм, әлбәттә, тәжрибәле житәкче С.А.Радыновтан башка шундый тату коллектив килеп чыкмас иде, ди.

Һонәри бәйрәм алдыннан, тугыз ай эш нәтиҗәләре буенча, полиция лейтенанты Р.Н.Байчуринга, хезмәт вазыйфаларын намуслы башкаруы очен, оператив хезмәт эшчәнлегендә югары күрсәткечләр белән килгәне очен, аеруча катлаулы һәм моһим би-ремнәрне үтәгән очен Мордовия Рес-публикасы эчке эшләр министрынын Рәхмәт хатын 10нчы ПП начальнигы С.А.Радынов тапшырган. Бу әлегә Радик Наиль улынын беренче бүләге.

С.А.Радынов сүзләренә караганда, Радик Наиль улы, чыннан да әлеге бүләккә лаек. Ул эшкә жаваплы, намус белән карый. Тапшырылган участокны яшь участковый яхшы белә. Кешеләр ана ышаналар, анын турында унай фикерләр әйтәләр. Барлык документацияне законнарны белеп, дорес алып бара. Халыкнын барлык гозерләренә ул һәрвакыт тиз арада жавап бирә, территориядә тәртипне күзәтеп тора һәм торле мәсьәләләрдә һәрторле ярдәм күрсәтә, ди.

Сүз унаеннан, Радик кураторлык иткән участокларнын берсендә, Латышовка авылында яши. Биредә анын йорты, биредә туган, мәктәптә укыган... Житәкчеләре фикеренчә, яшь кешенен, Радик Наилевичнын, житмәгән бердәнбер нәрсәсе бар – ул үз гаиләсе юклыгы, хатыны һәм балалары. Тик бу анын киләчәктә, карьерасы кебек үк; бик яшь бит әле ул.

Наилә НАСЫРОВА